| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 Казан ш. № 433-20/э-2021

«Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2022 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2021-2025 елларга аерым

тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 № 433-20/э-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 2021 | 121 935,17 | 126,30 | 0,57157 | 121 935,17 | 126,30 | 0,57157 |
| | | 2022 | 108 190,33 | 131,21 | 0,57772 | 108 190,33 | 131,21 | 0,57772 |
| | | 2023 | 133 667,74 | 131,36 | 0,61947 | 133 667,74 | 131,36 | 0,61947 |
| | | 2024 | 137 530,76 | 131,36 | 0,63358 | 137 530,76 | 131,36 | 0,63358 |
| | | 2025 | 141 515,67 | 131,36 | 0,64813 | 141 515,67 | 131,36 | 0,64813 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 № 433-20/э-2021 карары редакциясендә) 3 нче кушымта

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесенең (югалтуларны исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме Татарстан Республикасында | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 2021 | 173 918,58 |
| | | 2022 | 154 314,03 |
| | | 2023 | 190 652,97 |
| | | 2024 | 196 162,87 |
| | | 2025 | 201 846,63 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге